Кушымта

**Үзәкләшкән дини оешма — Татарстан Республикасы**

**мөселманнарының Диния нәзарәте**

«Раслыйм»
ҮДО – ТРМДН рәисе, Мөфти
Камил хәзрәт Сәмигуллин
__________________________
«9» 02 2015 ел

***МӘЧЕТ КАРШЫНДАГЫ КУРСЛАР ӨЧЕН***
***ДИНИ ТӘРБИЯ ПРОГРАММАСЫ***

Программа Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте

Фән һәм мәгариф бүлеге тарафыннан әзерләнде.

Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәтенең
Голәмәләр шурасы хуплавы белән нәшер ителә.

## *Кереш сүз*

الْحَمْدُ لِلَّهِ نَحْمَدُهُ نَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنَعُوذُ بِاللَّهِ مِنْ شُرُورِ أَنْفُسِنَا وَ مِنْ سَيِّئَاتِ أَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللَّهُ فَلا مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْ فَلا هَادِيَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ

Ислам дине инсаннарда гаделлек, шәфкатьлелек, кешелеклелек, сабырлык сыйфатларын тәрбияли. Динебез үрнәк, яхшы, күркәм гамәлләр кылырга чакырып, җәмгыятебезнең әхлакый торышын билгели.

Асыл дини тәрбия һәм әдәп барча кешеләр өчен мөһим булган, беркайчан да эзсез югалмас хәзинә ул. Кешедә булырга тиешле иң зур байлык һәм кирәкле сыйфат — тәрбиялелек һәм әхлак.

Коръән безне: «Һидәятле, туры юлның ахыры — шатлык һәм җәннәт», — дип өйрәтә.

Балалар тәрбияләүгә Аллаһы тәгаләнең илчесе Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм гаять зур мәртәбә һәм әһәмият биргән. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер мөбарәк хәдисендә: «Балаларыгызга кадер-хөрмәт күрсәтегез, аларны асыл кешеләр итеп тәрбияләгез», — дигән. Шулай ук Аллаһы рәсүленең шундый сүзләре дә бар: «Һичбер ата баласына яхшы әдәптән артык бүләк калдырмас». Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бу хәдисләреннән ачык аңлашыла: тәрбия эше — иң төп, иң изге бурыч булып тора. Гаиләләрнең дәвамы — балаларда. Җәмгыятебезнең киләчәге исә тәрбияле әхлаклы буыннар кулында.

Менә шуңа, Аллаһы тәгалә ярдәмендә төшенеп, үзебезне, башкаларны, ягъни туганнарыбызны, дусларыбызны, балаларыбызны иманлы, инсафлы итәргә тырышу;

җәмәгатьчелеккә ислам әхлагын, тәрбиясен җиткерү бик әһәмиятле, шул ук вакытта зур тырышлык сорый торган гамәл.

«Мәчетләр каршындагы курслар өчен дини тәрбия программасы» тәрбияви эшчәнлек алып баруда булышлык күрсәтү ниятеннән әзерләнде. Бу программа мәчетләрдә хезмәт итүче имамнарга, мөгаллимнәргә, дини тәрбия кылучыларга тәкъдим ителә.

Хак Сүбхәәнәһү вә тәгалә эшләребезне кабуллардан әйләсә иде. Дин кардәшләребезгә китап файдасын күрергә, ислам тәрбиясен таратырга язсын.

***Татарстан Республикасы мөфтие***
***Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН***

# Тәрбия планы

| Дини тәрбия юнәлешләре |
| --- |
| 1. Әдәп-әхлак. |
| 2. Гакыйдә. |
| 3. Тәҗвид. |
| 4. Фикъһе. |
| 5. Коръән. |
| 6. Сира. |
| 7. Гарәп теле. |

# 1. Исламда әдәп-әхлак

## Беренче ел

**1.** Кереш. Әдәп-әхлаклы булу бу дөньяда да һәм ахирәттә дә бәхеткә ирешү.

**2.** Әдәп-әхлак төшенчәсе һәм аның ислам динендә тоткан урыны.

**3.** Әдәпнең мөселман өчен әһәмияте.

**4.** Аллаһ Тәгаләгә карата мөнәсәбәт.

**5.** Әдәпле булуда Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.с.нең үрнәге.

**6.** Диндә үрнәк булу. «Мөселман мөселманның көзгесе». Ихласлык. Тәкъвалык.

**7.** Белем алу әдәбе. Укытучы сайлау әдәбе. Китап уку әдәбе.

**8.** Коръән уку әдәбе.

**9.** Намаз уку әдәбе. Ураза тоту әдәбе. Садака әдәбе. Рия һәм аның төрләре.

**10.** Мәчет әдәбе. Җомга көне әдәбе.

**11.** Кешенең үз-үзенә карата мөнәсәбәте.

**12.** Ата-анага, туганнарга, дин кардәшләргә карата мөнәсәбәт.

## Икенче ел

**1.** Кереш. Ватан һәм милләтебезгә карата вазыйфаларыбыз.
**2.** Күркәм холыклар:
- Тугрылык;
- Тырышлык;
- Юмартлык;
- Мәрхәмәтлек;
- Тыйнаклык;
- Дуслык;
- Сабырлык;
- Шөкер итү;
- Олыларны хөрмәт итү;
- Хаклык һәм гаделлек;
- Әманәт;
- Сүздә тору;
- Ихласлык;
- Гафу итү.

**3.** Ямьсез холыклар:
- Ялган;
- Гайбәт һәм яманлау;
- Урлашу;
- Кеше үтерү;
- Аракы, хәмер эчү;
- Зина кылу;
- Тәкәбберлек;
- Исраф;
- Көнчелек.

**4.** Өйләнү, гаилә һәм ислам әдәбе.
**5.** Ир белән хатын-кыз мөнәсәбәте. Ирнең хаклары һәм вазифалары. Хатынның хаклары һәм вазифалары. Кыз һәм кияү сайлау.
**6.** Балаларга карата мөнәсәбәт.
**7.** Күршеләргә карата мөнәсәбәт. Мөселман булмаган кешеләргә карата мөнәсәбәт. Җәмгыятькә карата мөнәсәбәт.

**8.** Очрашу һәм сәлам бирү әдәбе. Сөйләшү әдәбе. Җыелыш әдәбе.

**9.** Йортка керү әдәбе. Кунак әдәбе. Ашау әдәбе.

**10.** Авыруны зиярат кылу әдәбе.

**11.** Үлемне истә тоту. Тәүбә. Үз-үзеңә хисап кылу.

**12.** Дога кылу һәм зикер әдәбе.

## Өченче ел

**1.** Кереш. Узган материалны кабатлап искә алу. Хәләл белән хәрамны аеру.
**2.** Мал кәсеп итү әдәбе. Тырышлык һәм ялкаулык. Хәерле гамәлләрдә ярышу. Тәвәккәллек.
**3.** Юл йөрү әдәбе.
**4.** Хаҗәт үтәү әдәбе.
**5.** Кыюлык һәм куркаклык. Юашлык һәм горурлык.
**6.** Мактау һәм мактану.
**7.** Шаяру әдәбе.
**8.** Көнчелек. Ачу килү. Тәнкыйть.
**9.** Гайбәт, бөһтан һәм сүз йөртү. Гафу үтенү һәм гафу итә белү.
**10.** Саранлык һәм юмартлык. Исраф итү.
**11.** Вакытның кадерен белү әдәбе.
**12.** Аллаһ Тәгаләнең мәхлүкатларына карата мөнәсәбәт (хайваннарга, үсемлекләргә һ.б.).
**13.** Диндә урталык.

**Татар телендә әдәбият:**


**1.** Әхлакый тәрбия дәресләре. — Казан: «Иман» нәшр., 2003. — 104 б.
**2.** Әхлак дәресләре. — Казан, 2010. — 128 б.
**3.** Балаларга үгет-нәсыйхәт. Яңартылган икенче басма. — Казан: «Дом печати», 2002. — 175 б.
**4.** Фазлыев Җ. Иманлы бала. Тәрбия турында. — Казан: «Идел-пресс» басмаханәсе, 2003. — 144 бит.
**5.** Валиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. Дәреслек. — Казан, 2013 — 256 б.
**6.** Валиуллин К.Х. «Ислам тәрбиясе» дәресләрен укыту методлары. Укыту әсбабы. — Яр Чаллы: «Ислам нуры» эшмәкәрлек үзәге. — 2013. — 193 б.
**7.** М. Түнтәри. Исламда хатыннарның хокукы.
**8.** Ризаэтдин Фәхретдин. Шәкертлек әдәбе. — Казан: «Иман» нәшр., 2002. — 56 б.

**Рус телендәге әдәбият:**


**1.** Адабы / Автор: Имам Абу Хамид аль-Газали, Казань: Идел-Пресс, 2013. 80 с.

**2.** Җәлил хәзрәт Фазлыев. Локман хәким нәсыйхәтләре. — Казан: ИД «Хузур», 2014. — 64 б.

**3.** Мустафа Чагрыджи. Мусульманская нравственность. — Казань: Российский исламский университет, 2010. — 218 с.

**4.** Рассказы и назидания из Тафсира «РУХУЛЬ-БАЯН». — Казань, 2014. 256 стр.

# 2. Гакыйдә

## Беренче ел

**1.** Гакыйдә нәрсәне өйрәнә? Гакыйдә фәненең бүтән фәннәрдән аермасы һәм мөһимлеге.
**2.** Ислам һәм иман.
**3.** «Лә иләһә иллә Аллаһү» кәлимәсенең тәрҗемәсе һәм мәгънәсе.
**4.** «Мөхәммәдү расүлүллаһ» кәлимәсенең тәрҗемәсе һәм мәгънәсе.
**5.** Иман һәм аның нигезләре.
**6.** Аллаһка карата иман. Аллаһның барлыгына һәм берлегенә дәлилләр. Әбү Хәнифә дәлилен күрсәтергә.
**7.** Аллаһның исемнәре һәм сыйфатлары.
**8.** Фәрештәләргә ышану. Фәрештәләрнең сыйфатлары һәм бурычлары. Җеннәр.
**9.** Пәйгамбәрләргә ышану. Пәйгамбәрләр турында мәгълүматлар.
**10.** Пәйгамбәрләр җибәрелүнең максаты. Аларның сыйфатлары.
**11.** Пәйгамбәрләрнең могҗизалары.
**12.** Мөхәммәд (с.г.с) пәйгәмбәрнең башка пәйгәмбәрләрдән аермасы. Аның кыскача биографиясе.
**13.** Китапларга ышану. Китаплар турында мәгълүматлар (нинди китаплар һәм нинди пәйгәмбәрләр аркылы иңгән?) Коръәннең үзенчәлеге.
**14.** Кыямәт көненә ышану. Кыямәт килүнең галәмәтләре. Кыямәт көне турында сөйләүче Коръәннән һәм пәйгәмбәребезнең сөннәтеннән аятьләр һәм хәдисләр.

## Икенче ел

**1.** Кыямәт көне турында сөйләшү.
**2.** Ахирәт.
**3.** Кабер. Иманлы һәм имансыз кешенең кабердәге хәле. Сорау.
**4.** Кыямәт көненең зур һәм кечкенә галәмәтләре.
**5.** Масих Дәҗҗәл чыгуы.
**6.** Гайсә (г.с)нең икенче килүе.
**7.** Яҗүҗ һәм Мәҗүҗ кавемнәре чыгуы.
**8.** Дабба чыгуы.
**9.** Ай тотылу.
**10.** Бөтен җир шарын төтен каплау.
**11.** Кояшның көнбатыштан чыгуы.
**12.** Ут барлыкка килү.
**13.** Кабердән кубарылу. Хисап.
**14.** Җәннәт. Җәннәт нигъмәтләре.
**15.** Җәһәннәм. Җәһәннәм газаплары.
**16.** Пәйгәмбәребезнең шәфәгате.
**17.** Тәкъдир. Тәкъдирнең хикмәте. Тәкъдиргә ышануның файдасы. Кайбер кешеләрнең гөнаһ эштә тәкъдир белән акланувы. Һәр кеше өстендә бу дөньяда эшләгән гамәлләре өчен җаваплылык тоту.

## Өченче ел

**1.** Кереш.
**2.** Кешенең бу дөньяда яшәүнең максаты.
**3.** Аллаһ Тәгаләгә буйсыну. Гыйбадәт.
**4.** Савап һәм гөнаһ.
**5.** Зур һәм кечкенә гөнаһләр.
**6.** Гөнаһның җәзасын бетерүче сәбәпләр.
**7.** Хәләл һәм хәрам.
**8.** Көфер. Көферлеккә билгеләмә.
**9.** Ширек.
**10.** Мәзһәбләр. Әбү Хәнифә мәзһәбенең мәшһүр галимнәре (имам Әгъзам Әбү Хәнифә, Әбү Йосыф, Мөхәммәд, Зөфәр). Имам Матуриди.
**11.** Диннәр. Христиан дине. Иудаизм. Буддизм.
**12.** Сөннәт әһелләреннән аерылмау һәм фиркаларга иярмәү. Безнең региондагы фиркалар (Ваһһабчы — сәләфиләр, шигыйлар, тәхрирчеләр, тәблигчылар, нурсичылар һ.б.).

**Татар телендә әдәбият:**


**1.** Әхмәдһади Максуди. Гыйбадәте исламия. — Казан: Идел-Пресс, 2013. — 112 б.
**2.** Әдһәм Габдулла. Гакыйдә. Укыту әсбабы. — Казан, 2013.
**3.** Ислам гакыйдәсе (иман нигезләре). / Тулыландырылган һәм үзгәртелгән икенче басма. Төзүче: Камил Хәмзә улы Вәлиулла. — Казан: «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе, 2002. — 192 бит.
**4.** Мөхәммәт Әбү Зәһра. Әбү Хәнифә. — Казан: «Иман» нәшр.,2008. — 544 б.
**5.** М. Кифаятуллаһ. Хәнәфи мәзһәбе буенча ислам тәгълимәте. Казан: «Иман» нәшр.,2005. — 40 б.
**6.** Ягъкуб Вәлиулла. Рәсми булмаган Ислам Татарстанда: хәрәкәтләр, агымнар, секталар. — Казан: «Иман» нәшр., 2003. — 36 б.

**Рус телендәге әдәбият:**

**1.** Ахмадхади Максуди. Ибадат аль-Исламия. — Казань: Идел-Пресс, 2013. — 112 с.
**2.** «Акыда Ат-Тахавия» / Автор: Имам Абу Джа'фар ат-Тахави. ИД «Хузур», Казань: Идел-Пресс, 2013. 1-е издание, 48 с.
**3.** Адыгамов А. Акыда (Исламское веоучение), учебное пособие. — Казань, 2012. — 159 стр.
**4.** Имам Матуриди (сборник). — Казань: Иман, 2010. — 48 с.
**5.** Шахрастани. Книга о религиях и сектах. Часть I/ Ислам / Пер., введ. и коммент. С.М. Прозорова. М.: Наука: ГРВЛ, 1984.

# 3. Тәҗвид

## Беренче ел

**1.** Гарәп теле турында кыскача төп мәгълүмат. Тәҗвид — Коръәнне дөрес итеп уку кагыйдәләре.
**2.** Гарәп әлифбасы.
**3.** Гарәп хәрефләренең исемнәре.
**4.** Гарәп хәрефләре исемнәрен дөрес итеп әйтергә өйрәнү.
**5.** Гарәп әлифбасын ятлау.
**6.** Гарәп хәрефләрен язарга өйрәнү. Хәрефләр язылышының дүрт төрле шәкеле (формасы): аерым, сүз башында, сүз эчендә һәм сүз ахырында язылышы. Күнегүләр.
**7.** Хәрәкәләр: фәтхә, кәсрә, даммә.
**8.** Хәрәкәләр ярдәмендә гарәп хәрефләрен уку һәм язу рәвешләре.
**9.** Сәкен. Хәрәкәле һәм сәкенле хәрефләрне язу һәм уку.
**10.** Хәрәкәле һәм сәкенле хәрефләрне кушып сүзләр уку һәм язу.
**11.** Охшаш хәрефләр.
**12.** Калын һәм нечкә хәрефләр.
**13.** Мәдле хәрефләр (әлиф, уау, йа).
**14.** Тәшдид.
**15.** Тәнвин.
**16.** Тәнвинле тәшдид.
**17.** Һәмзәнең язылу төрләре.
**18.** «Тә» мәрбута.
**19.** Калькалә хәрефләр.
**20.** Сүзләрдә үзләре язылмасалар да укыла торган хәрефләр.
**21.** Сүзләрдәге хәрәкәсез «йа» хәрефенең «әлиф» булып укылуы.
**22.** Сүзләрдә «уау» хәрефенең «әлиф» булып укылуы.
**23.** Сүзләрдә язылса да укылмый торган хәрефләр.
**24.** Исемнәргә «билгелелек ләм»ен кертү.
**25.** Изһар камәрия кагыйдәсе.

**26.** Идгам шәмсия кагыйдәсе.
**27.** Вакыф — тыныш.
**28.** Мукаттагаһ хәрефләре.
**29.** Сәкенле «нун» һәм тәнвин кагыйдәләре:
— Изһар;
— Икъләб;
— Идгам би гуннәһ;
— Идгам бигайри гуннәһ;
— Ихфа мәгәл-гуннәһ.
**30.** Мәдләрнең төрләре:
— Мәд тәбигый;
— Мәд муттасыйл;
— Мәд мунфасыйл;
— Мәд гарыз;
— Мәд ләзем;
— Мәд лин;
— Мәд гыйуад;
— Мәд сыйлә.
**31.** Сәкенле мим кагыйдәсе.
— Идгам мисләйн;
— Идгам мүтәкарибәйн;
— Идгам мүтәҗәнисәйн.
**32.** «Ләм» хәрефе кагыйдәсе. Ләфзатуллаһ.
**33.** «Ра» хәрефе кагыйдәсе.
**34.** «Һә» хәрефе кагыйдәсе.
**35.** Әлиф кагыйдәсе.
**36.** Һәмзәтүл васыйл булган сүзләрне уку.
**37.** Сәктә кагыйдәсе.
**38.** Тәксир-тәнвин кагыйдәсе (тәнвинне кәсрәле итеп уку).
**39.** Коръән укуны башлау һәм тәмамлау кагыйдәләре.

**Татар телендә әдәбият:**


**1.** Әхмәдһади Максуди. Мугаллим сәни. Казан, 2004.
**2.** Вәлиуллин Камил. Гәрәпчә язу. 1 һәм 2 өлеше. — Казан: «Иман» нәшр., 1996. — 25 б.

**3.** Коръән Кәрим.
**4.** Камил Вәлиуллa. Тәҗвид кагыйдәләре. — Казан: Мөхәммәдия мәдрәсәсе, 2008. — 48 б.
**5.** Мөбарәк Җ. Тәҗвид кагыйдәләре. — Казан: «Иман» нәшр., 2005. — 32 б.
**6.** Салихҗан Әл-Баруди. Фән Тәҗвид. — Казан, 1999.
**7.** Саматов Габделхак хәзрәт. Гарәп хәрефләрен үзлегеңнән өйрәнү өчен кулланма. Казан: «Иман» нәшр., 2005. — 59 б.
**8.** Карабаш. Тәҗвид.

# 4. Фикъһе

## Беренче ел

**1.** Кереш. Фикъһе нәрсәгә кирәк? Гамәлләр, хөкемнәр һәм аларның төрләре (фарыз, ваҗиб, сөннәт, мөстәхәб, мөбах, мөстәкрәһ, мәкруһ, хәрам).
**2.** Фикъһе нигезләре (чыганаклары): Коръән Кәрим, Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.с.нең Сөннәте, иҗмаг, кыяс.
**3.** Мәзһәбләр. Имам Әгъзам Әбү Хәнифәнең тормыш юлы. Әбү Хәнифә мәзһәбенең безнең мохиткә туры килүе һәм бүтән мәзһәбләргә карата актуальлелеге. Хәнәфи мәзһәбенең мәшһүр галимнәре.
**4.** Тәһарәтнең фарызлары һәм сөннәтләре.
**5.** Тәһарәтнең мөстәхәбләре һәм мәкруһлары.
**6.** Тәһарәтне боза торган гамәлләр.
**7.** Тәһарәт өчен кирәк гамәлләр.
**8.** Читекләргә мәсех кылу.
**9.** Җәбирә яки яра бәйләнгән җиргә мәсех кылу.
**10.** Госел алу өчен кирәк гамәлләр.
**11.** Госелнең фарызлары һәм сөннәтләре.
**12.** Тәяммум алу һәм аны рөхсәт итүче сәбәпләр.
**13.** Тәяммумның фарызлары һәм сөннәтләре.
**14.** Тәяммумның дөреслеген боза торган гамәлләр.
**15.** Нәҗес һәм аның төрләре.
**16.** Нәҗесләрдән пакьләү.
**17.** Хаҗәтне үтәү.
**18.** Пакьләнү.
**19.** Пакь сулар.
**20.** Кое.
**21.** Гаурәт.
**22.** Гозерле хатыннар.
**23.** Намаз.
**24.** Намаз кемгә фарыз.
**25.** Намазның вакытлары.

**26.** Кыйбла.
**27.** Ният.
**28.** Азан һәм азан шартлары.
**29.** Мөәззин шартлары.
**30.** Камәт.
**31.** Намазның зикерләре.
**32.** Ике рәкәгатьле намаз.
**33.** Дүрт рәкәгатьле намаз.
**34.** Витр-ваҗиб намаз.
**35.** Хатыннар намазы.
**36.** Тәсбих һәм дога.
**37.** Зәгыйфь кешенең намазы.
**38.** Намазның шартлары.
**39.** Намазның рөкеннәре.
**40.** Намазның ваҗиблары.
**41.** Намазның сөннәтләре.
**42.** Намазның мөстәхәбләре.
**43.** Намазның мәкруһлары.
**44.** Намазның мөфсидләре.
**45.** Намазда мөбах булган эшләр.
**46.** Намазның казасы.

## Икенче ел

**1.** Җәмәгать.
**2.** Мөдрик һәм мәсбук.
**3.** Мәсҗид һәм җамигъ.
**4.** Сәҗдәи сәһү.
**5.** Намазда саташу.
**6.** Сәҗдәи тиләвәт.
**7.** Мокыйм һәм мөсафир.
**8.** Җомга намазы һәм аның шартлары.
**9.** Җомганың сөннәтләре.
**10.** Җомганың әдәпләре.
**11.** Гает намазлары.
**12.** Тәравих намазы.
**13.** Җеназа намазы.
**14.** Мәетне юу.
**15.** Кәфенләү.
**16.** Мәетне озату, кабер.
**17.** Мәетнең туганнарын юату, каберләрне зиярат кылу һәм дога кылу.
**18.** Нәфел намазлары.
**19.** Ураза һәм аның шартлары.
**20.** Уразаның фарызлары.
**21.** Уразаның мөстәхәбләре һәм мәкруһлары.
**22.** Уразаны боза һәм бозмый торган гамәлләр.
**23.** Сөннәт һәм нәфел уразалары.
**24.** Игътикяф.
**25.** Игътикяфнең мәкруһлары һәм аны боза торган гамәлләр.
**26.** Зәкят һәм ул кемнән чыгарылырга тиешле.
**27.** Зәкят маллары. Зәкят малы кемгә бирелә.
**28.** Нисаб.
**29.** Гошер.
**30.** Фитр.
**31.** Фидия.
**32.** Садака.

**33.** Корбан.
**34.** Хаҗ. Хаҗның гомрәдән аермасы һәм ул кемгә тиешле.
**35.** Хаҗның шартлары һәм микат.
**36.** Хаҗның фарызлары һәм ихрам.
**37.** Хаҗның ваҗибләре.
**38.** Хаҗның сөннәтләре.
**39.** Хаҗ гамәлләре.
**40.** Гомрәнең гамәлләре.
**41.** Төрле догалар.
**42.** Һиҗри айлар.
**43.** Бәйрәм көн һәм кичәләр.

## Өченче ел

1. Кереш. «Сәүдә». Сәүдәнең рөкеннәре.
2. Сәүдәнең шартлары.
3. Сәүдәнең төрләре.
4. Сәүдәнең тыелган төрләре.
5. Монополия, бәяне билгеләү, килешүне өзү, арадашлык.
6. Риба.
7. Җирне һәм уңышны сату.
8. Бәясен алдан түләп сатып алу һәм тауарны эшләтү.
9. Бурыч һәм аны кемгә күчерү.
10. Аренда.
11. Бүләкләр.
12. Әманәткә биреп тору.
13. Хәергә бирелгән мал-мөлкәт.
14. Табылдык.
15. Хәләл ризыклар.
16. Хәрам ризыклар.
17. Нәзер.
18. Никах, аның хөкемнәре, шартлары, рөкеннәре.
19. Вәли, мәһер, шаһидләр, һәм аларның шартлары.
20. Тыелган никахлар.
21. Никахлашырга тыелган туганнар.
22. Сөт туганлыгы.
23. Ярәшү, никахның барышы һәм никах мәҗлесе.
24. Ир белән хатынның вазыйфалары һәм хаклары.
25. Талак төшенчәсе һәм аның хөкеме.
26. Талакның шартлары һәм төрләре.
27. Гыйддә, аның төрләре һәм дәвере.
28. Кешенең билгесез югалуы.
29. Үги бала алу.
30. Шәригать һәм гореф-гадәт.

**Татар телендә әдәбият:**

**1.** Әхмәдһади Максуди. Гыйбадәте исламия. — Казан: Идел-Пресс, 2013. — 112 б.
**2.** Габделхак Саматов. Шәригать (3 китапта). — Казан: Идел-Пресс, 2005.
**3.** Камил хәзрәт Сәмигуллин. Ураза. — Казан: ИД «Хузур», 2014. — 160 б.
**4.** Мөхәммәд Гашыйк. Ислам шәригате. Һәркемгә урешерлек фикх мәсьәләләре (әт-тәсһил әз-зарури ли мәсәил әл-Кудури)./2 кисәктә. — Казан: «Иман» нәшрияте, 2000 ел.
**5.** Мухаммад Абдуллах бин Муслим аль-Бахлави. Хәнәфи мәзхәбенең дәлилләре. — Казан, 2011. — 447 б.
**6.** Нургалеев Р.М. Әбү-Хәнифә мәзһәбе буенча намаз уку рәвеше. — Яр Чаллы шәһәре «Ислам нуры» эш-мәкерлек үзәк — 2012. — 37 б.
**7.** Р.Г. Батров. Әбү-Хәнифәнең тормышы һәм мирасы. Беренче кисәк. — Казан: Татарстан Фәннәр Академиясе тарих Институтыю — 2008. — 320 б.
**8.** Сөннәт буенча намаз уку рәвеше яки хәнәфи мәзһәбе буенча намаз уку тәртибен билгеләүче дөрес хәдисләр. — Казан: «Иман» нәшр., 2006. — 19 б.
**9.** Җеназа китабы. Хәнәфи мәзһәбе буенча күмү тәртибе. — Казан: «Иман» нәшр., 2000. — 54 б.
**10.** Фазлыев Җ. Имам һәм мәчет. — Казан: «Иман» нәшр., 2010. — 64 б.

**Рус телендәге әдәбият:**

**1.** Ахмадхади Максуди. Ибадат аль-Исламия. — Казань: Идел-Пресс, 2013. — 112 с.
**2.** Адыгамов Р. К. Основы мусульманского права. — Казань: «Иман», 2011.
**3.** Пост по мазхабу Абу Ханифы, 1-е издание. — Казань: Идел-Пресс, 2013. 80 стр.

**4.** Фазлыев З.В. Основы исламской культуры: учебное пособие / З.В. Фазлыев. — Казань: «Иман», 2009. — 144 с.
**5.** Якупов В. Ханафитский мазхаб, его значение и актуальность. — Казань: ИД «Хузур», 2014. — 36 с.

# 5. Коръән

## Беренче ел

***Коръән Кәрим турында мәгълүмат:***

**1.** Коръән — Аллаһ Тәгаләнең китабы.
**2.** Вәхи. Вәхинең төрләре һәм үзенчәлекләре.
**3.** Коръән иңдерелүенең кыскача тарихы.
**4.** Коръәннең үзенчәлекләре һәм өстенлекләре.

***Зикерләр һәм догалар:***

**1.** «Истигазәһ» һәм «Бәсмәләһ».
**2.** Сәламләшү кәлимәләре.
**3.** Тәкбир, Тәхмид, Тәсбих.
**4.** Иман кәлимәләре.
**5.** Тәһарәт, госел алдыннан һәм тәһарәт, госел алганнан соң укыла торган зикерләр һәм догалар.
**6.** Намаз алдыннан һәм намаздан соң укыла торган зикерләр һәм догалар (сәнә догасы, азан догасы).
**7.** Намазда укыла торган зикерләр (кыямда, рөкүгътә, сәҗдәдә, кагъдәдә һ.б.), догалар («раббәнә әтинә», кунут догасы, һ.б.), кыска сүрәләр, аятьләр.
**8.** «Тәсбих» догасы һәм «Сәҗдәи тиләвәт» догасы.
**9.** «Тәүбә — истигъфәр» догасы.

***Коръәндәге сүрәләрне уку, ятлау һәм тәфсирләре белән танышу:***

*Сүрәләр:*

**1.** «Әл-Фатиха».
**2.** «Әл-Ихлас».
**3.** «Әл-Фәлак».
**4.** «Ән-Нәс».
**5.** «Әл-Мәсәд».
**6.** «Ән-Наср».
**7.** «Әл-Кәфирүн».

**8.** «Әл-Кәүсәр».
**9.** «Әл-Мәгүн».
**10.** «Курайш».
**11.** «Әл-Фил».
**12.** «Әл-Һүмәзәһ».
**13.** «Әл-Гаср».

## Икенче ел

***Коръән Кәрим турында мәгълүмат:***

**1.** Кереш.

**2.** Коръәннең җыелуы. Коръәнне бастыру тарихы. Казан басмасы.

**3.** Коръәндә сүрәләрнең, аятьләрнең урнашу тәртибе.

**4.** Коръән тәфсире. Коръәнгә тәфсир кылуның әдәбе һәм шартлары.

**5.** Мәшһүр мөфәссирләр (тәфсир кылучылар) һәм алар язган тәфсир китапларының исемнәре.

**6.** Коръәнгә карата вазифаларыбыз.

***Зикерләр һәм догалар:***

**1.** Мәчеткә кергәндә һәм мәчеттән чыкканда укыла торган догалар.

**2.** Рамазан аенда укыла торган зикерләр һәм догалар.

**3.** Хаҗда һәм Корбан гаетендә укыла торган зикерләр һәм догалар.

**4.** Йортка кергәндә һәм йорттан чыкканда укыла торган дога, сәфәр догасы.

**5.** Еш кулланыла торган башка зикерләр һәм догалар (ашау алдыннан һәм ашаганнан соң, йокы алдыннан һәм йокыдан уянгач, бәдрәфкә кергәндә һәм чыкканда, төчкергәч һ.б.).

***Коръәндәге сүрәләрне уку, ятлау һәм тәфсирләре белән танышу:***

*Сүрәләр:*

**1.** «Әт-Тәкәсүр».

**2.** «Әл-Каригаһ».

**3.** «Әл-Гадият».

**4.** «Әз-Зәлзәләһ».

**5.** «Әл-Бәййинәһ».

**6.** «Әл-Кадр».

**7.** «Әл-Гәлак».
**8.** «Әт-Тин».
**9.** «Әш-Шәрх».
**10.** «Әд-Духа».
**11.** «Әл-Ләйл».
**12.** «Әш-Шәмс».
**13.** «Әл-Бәләд».
**14.** «Әл-Фәҗр».

***Коръән сүрәләреннән аятьләр уку һәм аларның тәфсирләре белән танышу:***

**1.** «Әл-Бәкара» сүрәсенең 163 — 167, 183 — 185, 284 — 286 аятьләре.
**2.** «Ясин» сүрәсенең 1 — 83 аятләре.
**3.** «Әл-Хәшр» сүрәсенең 20 — 24 аятьләре.
**4.** «Әл-Фәтх» сүрәсенең 1 — 29 аятьләре.
**5.** «Әл-Әхзаб» сүрәсе.

## Өченче ел

***Коръәндәге сүрәләрне уку, ятлау һәм тәфсирләре белән танышу:***

*Сүрәләр:*

**1.** «Әл-Гашияһ».
**2.** «Әл-Әглә».
**3.** «Әт-Тарик».
**4.** «Әл-Буруҗ».
**5.** «Әл-Иншикак».
**6.** «Әл-Мутаффифин».
**7.** «Әл-Инфитар».
**8.** «Әт-Тәквир».
**9.** «Гәбәсә».
**10.** «Ән-Нәзигать».

***Коръән сүрәләреннән аятьләр уку һәм аларның тәфсирләре белән танышу:***

**1.** «Әр-Рәхман» сүрәсенең 1 — 78 аятьләре.
**2.** «Әл-Мәидә» сүрәсенең 72 — 76 аятьләре.
**3.** «Әл-Әнгам» сүрәсенең 29 — 63 аятьләре.
**4.** «Әл-Фуркан» сүрәсенең 63 — 77 аятьләре.
**5.** «Лукман» сүрәсенең 13 — 19 аятьләре.
**6.** «Әл-Хуҗурат» сүрәсенең 1 — 13 аятьләре.
**7.** «Әл-Мүлк» сүрәсенең 1 — 30 аятьләре.
**8.** «Ән-Нәбә» сүрәсенең 1 — 40 аятьләре.

**Татар телендә әдәбият:**

**1.** Коръән Кәрим.
**2.** Коръән Кәрим китабы (тәфсире һәм укылышы белән). — Казан: «Иман» нәшр., 2009. — 1172 б.
**3.** Догалык: тәсбихләр, хәмедләр, тәкбирләр, салаватлар, догалар. — Казан: «Иман» нәшр., 2007. — 352 б.
**4.** Ягез бер дога. Һәфтияк шәриф./Өченче китап. Китапны төзүче Җ.Фазлыев — Казан: 2002. — 151 бит.

**5.** Якупов В. М. Хаҗ һәм гомрә. Мәккә-Мәдинә буенча юл күрсәткече. Хаҗ догалары. — Казан: Иман, 2010. — 272 б.

**Рус телендәге әдәбият:**

**1.** Камиль Самигуллин. Каждый может стать Коран хафизом. Второе издание. Казань: ИД «Хузур», 2013. — 128 с.
**2.** Суютый Д. Совершенство в коранических науках: учение о ниспослании Корана. — М.: ИД «Муравей», 2001 г.

# 6. Сира. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.с)нең тормышы

## Беренче ел

1. Сира фәне нәрсәне өйрәнә.
2. Мөхәммәд (с.г.с.) килгәнче булган вазгыять.
3. Мөхәммәд (с.г.с.)нең нәселе.
4. Мөхәммәд (с.г.с.)нең тууы.
5. Мөхәммәд (с.г.с.)нең сөт анасы.
6. Фәрештәләр Мөхәммәд (с.г.с.)нең күкрәген ярулары.
7. Мөхәммәд (с.г.с.)нең әнисенең һәм әтисенең үлеме.
8. Мөхәммәд (с.г.с.)нең әтисенең абыйсында тәрбияләнүе.
9. Мөхәммәд (с.г.с.)нең Әш-Шамга сәфәре.
10. Мөхәммәд (с.г.с.)нең сугышта катнашуы.
11. Мөхәммәд (с.г.с.)нең өйләнүе.
12. Кәгъбәне төзекләндерү һәм кара таш вакыйгасы.

## Икенче ел

*Пәйгәмбәрлек еллары:*

**1.** Кереш. Беренче вәхи.
**2.** Беренче мөселманнар һәм яшерен дәгъват.
**3.** Ачык дәгъват һәм мөселманнарны эзәрлекләү.
**4.** Мөселманнарның Эфиопиягә хиҗрәт кылулары.
**5.** Мөселманнарның куәтләнүе.
**6.** Бойкот.
**7.** Кайгы елы.
**8.** Мөхәммәд (с.г.с.)нең Таифкә сәфәре.
**9.** Исра һәм миграҗ вакыйгасы.
**10.** Дәгъватның таралуы.
**11.** Ясриб әһелләренең Исламны кабул итүләре, бәйгать.
**12.** Һиҗрәт.
**13.** Һиҗрәттән соң Мәдинәдәге хәлләр.
**14.** Пәйгәмбәребез вакытында Ислам динен һәм дәүләтен басып алучылардан саклау сугышлары алып бару (Бәдр, Ухуд, Хандак, Му'тә, Хунәйн, Табук сугышлары).
**15.** Әл-Хөдәйбийә солыхы.
**16.** Патшаларга хат язу.
**17.** Мөхәммәд (с.г.с.)нең гомрә кылуы.
**18.** Мәккәнең алынуы.
**19.** Әбү Бәкр әс-Сыддыйк хаҗы.
**20.** Делегацияләр елы.
**21.** Насаралар делегациясе.
**22.** Мөхәммәд (с.г.с.)нең соңгы хаҗы.
**23.** Мөхәммәд (с.г.с.)нең авыруы һәм үлеме.
**24.** Мөхәммәд (с.г.с.)нең сыйфатлары.
**25.** Мөхәммәд (с.г.с.)нең хатыннары һәм балалары.

## Өченче ел

*Ислам тарихы һәм татар халкында исламның урыны:*

**1.** Хәлифәләр чоры.
**2.** Беренче хәлифә — Әбү Бәкр әс-Сыддыйк.
**3.** Икенче хәлифә — Гомәр ибне Хаттаб.
**4.** Өченче хәлифә — Госман ибне Гаффан.
**5.** Дүртенче хәлифә — Гали Әбү Талиб.
**6.** Ислам диненең хәлифәт чорында таралуы.
**7.** Хәлифәт таркалганнан соң Ислам диненең халәте.
**8.** Ислам тарихы.
**9.** Болгар бабаларыбызның исламны кабул итүләре.
**10.** Алтын Урда вакытында Ислам дине.
**11.** Казан ханлыгы. Кол Шәриф.
**12.** Татар зыялылары. Галимнәр һәм мәгърифәтчеләр.
**13.** 13. Безнең регионда ислам үсешенә зур өлеш керткән галимнәр, аларның тормыш юллары һәм әсәрләре (Ш. Мәрҗани, Г. Курсави, Г. Утыз-Имәни, З. Рәсүли, Г. Баруди, Р. Фәхретдин һ.б.).

**Татар телендә әдәбият:**


**1.** Бикбулатов С. Хәзрәти Мөхәммәд. — Казан: Хузур, 1436/2014. — 436 б.
**2.** Бикбулатов С. Дүрт хәлифә. — Казан, 2009. — 360 б.
**3.** Бикбулатов С. Ислам тарихы. — Казан, «Иман» нәшр., 2008. — 81 б.
**4.** Р. Фәхреддин. Мөхәммәд. — Казан: Хузур — Спокойствие, 2015 — 132 б.
**5.** Саматов Габделхак. Милләтебездә ислам дине. — Казан: «Иман» нәшр., 1997. — 190 б.
**6.** Таҗетдин Ялчыгол. Тәварихы Болгария. — Казан: ИД «Хузур», 2014. — 154 б.
**7.** Татар зыялылары: тарихи портретлар. / Төз. Р.М. Мөхәммәтшин. — Казан: Мәгариф, 2003. — 208 б.

**Рус телендә әдәбият:**

**1.** Р. М. Мухаметшин. Ислам и мусульманская культура в среднем Поволжье: история и современность. — Казань, «Фән», 2006.

**2.** Р. Фахреддин. Мухаммад. — Казань: Хузур — Спокойствие, 2015 — 132 с.

**3.** Р.М. Мухаметшин. История ислама: учеб. пос. — Наб. Челны: «Духовно-деловой центр «Ислам Нуры». — 2012. — 104 с.

**4.** М.М. Марданшин. История ислама (с углубленным изучением истории и культуры ислама): Учебное пособие. — Казань: Изд-во «Яз», 2012. — 208 с.

**5.** Сира: Жизнеописание пророка Мухаммада: Хрестоматия: В 2-х т. Т.1, Т.2, Ч.1, Ч.2. / Авт. сост. Т.К. Ибрагим, Н.В. Ефремов. — Казань: Магариф, 2008. — 319 с.

# 7. Гарәп теле

## Икенче ел

**1.** Кереш. Гарәп телендә тәҗвид һәм әдәби тел кагыйдәләре буенча укуның уртаклыгы һәм аермалыклары.
**2.** Исем, фигыль, һәм кисәкчә төшенчәләре.
**3.** Сарф һәм нәхү нәрсәләрне өйрәнә.
**4.** Гарәп телендә сүзләрнең ясалыш тәртипләре. Сүз тамыры.
**5.** Исем. Исемнәрнең билгелек һәм билгесезлек төрләре. Әлиф Ләм артикле.
**6.** Сан категориясе. Гарәп телендә сүзләрнең саннар буенча төрләнү үзенчәлекләре: берлек, икелек һәм күплек саннар.
**7.** Күплек сандагы исемнәрнең төзек һәм төзек булмаган төрләре.
**8.** Затлар. Зат алмашлыклары.
**9.** Исемнәрнең затлар буенча төрләнеше.
**10.** Исемнәрнең җенес категориясе буенча төрләнеше: ир һәм хатын-кыз җенесләренә караган исемнәрнең ясалышы.
**11.** Исемнәрнең затлар, җенесләр һәм саннар буенча төрләнеше.
**12.** Килеш категориясе. Исемнәрнең килешләр буенча төрләнеше.

## Өченче ел

**1.** Кереш.
**2.** Кисәкчәләр.
**3.** Күрсәтү алмашлыклары.
**4.** Нисби алмашлыклар.
**5.** Фигыльләр һәм аларның төрләре.
**6.** Үткән заман фигыле «Кәнә».
**7.** Хәзерге заман фигыле.
**8.** Киләчәк заман фигыле.
**9.** Боерык фигыль.
**10.** Фигыльләрнең затлар, җенесләр һәм саннар буенча төрләнеше.
**11.** Гарәп телендә җөмлә төзелеше тәртибе. Җөмлә төзүче кисәкләр.
**12.** Ия һәм хәбәр.
**13.** Исем җөмләсе.
**14.** Фигыль җөмләсе.


**Татар телендә әдәбият:**

**1.** Әхмәд Һади Максуди. Әш-Шифәһиййә. Әл-Җүз Әл-Әүвәл. — Казань: литотипография Н.Н.Харитонова, 1910. — 152 б.
**2.** Нуруллин Ф.С. Гарәп теле грамматикасы. — Казан: «Иман» нәшрияты, 1993. — 400 б.

**Рус телендәге әдәбият:**

**1.** А.А. Ковалев, Г.Ш. Шарбатов. Учебник арабского языка. Москва: «Восточная литература» РАН, 1998. — 751 с.
**2.** А.К. Мингалеев, Т.А. Шайхуллин. Грамматика арабского языка./Учеб. пособие. — Казань: «Иман», 2001. — 71 стр.
**3.** Х.К. Баранов. Словарь Арабско-Русский.
**4.** В.М. Борисов. Большой русско-арабский словарь.